РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«20» март 2024 ел Олы Кайбыч ав. № 252

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кайбыч муниципаль районы Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны фикер алышуга чыгарырга.

2. Расларга:

- гражданнарның «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Кайбыч муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе (2 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе (3 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

Гавамиа тыңлаулар үткәрү урыны итеп Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасын, гавами тыңлаулар үткәрү вакытын - 10.00 сәг кә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча эшче төркем төзергә:

Хәялиев Рәмис Рафис улы - төркем җитәкчесе.

төркем әгъзалары:

Сундурова Фәридә Абдулла кызы;

Матвеева Светлана Петровна;

Кузнецова Рушания Фәрит кызы.

5. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына төзәтмәләрне һәм тәкъдимнәрне өйрәнергә һәм гомумиләштерергә, тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы каравына кертергә.

6. Массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән «Кайбыч таңнары» («Кайбицкие зори») челтәр басмасында Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис А. И. Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2024 елның "20" 03
252 номерлы карарына
1 нче кушымта

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

« » ___________ 2024 ел Олы Кайбыч ав. №___

Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасының «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2019 елның 17 июнендәге 170 номерлы карары белән (05.08.2020 № 246, 18.10.2021, № 65, 01.12.2023 №229 үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт тарафыннан теркәү уздыру өчен юлларга.
3. Әлеге карарны «Кайбыч таңнары» («Кайбицкие зори» ) район газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башлыгы урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Рәис А.И.Рәхмәтуллин

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
__________ "___" ____________
____ номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр

1. 6 статьяның 1 өлешендәге 34 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34) Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен гамәлгә ашыру, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен билгеләү, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгеләү;».

2. 45 статьяның 1 өлешендәге 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясенең су законнарында билгеләнгән чикләрдә, су объектлары милекчесенең вәкаләтләрен, шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен гомуми файдаланудагы су объектларыннан файдалану кагыйдәләрен, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне дә кертеп, билгеләү, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләрен билгели;».

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2024 елның "20" 03
252 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуы турында» Кайбыч муниципаль районы Советы карар проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Кайбыч муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт, яисә 2-11-01, 2-11-85 факсы буенча, кушымта итеп бирелә торган үрнәк буенча төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язмача рәвештә

| № т/б | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, текст проекты | Төзәтмә авторы (ФИА, адресы,телефоны, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр массакүләм мәгълүмат чараларында карар басылып чыккан көннән утыз көн эчендә эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар, 7 нче йорт адресы буенча шәхсән яки почта аша («Уставка үзгәрешләр кертү турында фикер алышу» яки «гавами тыңлаулар» дигән тамга белән), шулай ук 2-11-01, 2-11-85 факсы буенча бирелә.

Гаризалар гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча эш көннәрендә 8 сәгатьтән 17 сәгатькә кадәр кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре теркәлә һәм Кайбыч муниципаль районы Советында төзелгән эш төркеме тарафыннан карала һәм карап тикшерү өчен законлылык, регламент һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Советының
2024 елның "20" 03
252 номерлы карарына
3 нче кушымта

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы
карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (алга таба - гавами тыңлаулар) үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар «Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 16 статьясы, әлеге Тәртип нигезендә уздырыла.

2. Гавами тыңлауларда катнашучылар булып үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән Кайбыч муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район халкы тора.

3. Гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукыннан башка гавами тыңлауларда районның барлык кызыксынучы халкы, массакүләм мәгълүмат чаралары катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланырга 1 сәгать кала башлана.

5. Гавами тыңлауларда рәислек итүче булып муниципаль берәмлек Башлыгы яисә, аның кушуы буенча, муниципаль берәмлекнең башка вазыйфаи заты тора.

6. Гавами тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән ачыла, ул утырышта катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе турында хәбәр итә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариатның җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында ачык тыңлаулар секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән Кайбыч муниципаль районы Советы депутаты, законлылык, регламент һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссия карары белән вәкаләтле вәкил чыгыш ясый.

9. Гавами тыңлауларда катнашучылар, чыгыш ясау хокукы белән, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

10. Гавами тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 7 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел. Рәислек итүче рөхсәте белән чыгыш ясау өчен вакыт озайтылырга мөмкин, ләкин 3 минуттан да артыкка түгел.

11. Гавами тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш ясаганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Гавами тыңлаулар уздырганда тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче гавами тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә гавами тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, тәкъдимнәрне ачыклау өчен сүз бирә ала.

16. Гавами тыңлауларда катнашучыларның барлык кисәтүләре һәм тәкъдимнәре секретариатка язма рәвештә тапшырыла һәм гавами тыңлаулар беркетмәсенә кушыла. Гавами тыңлаулар беркетмәсенә рәислек итүче кул куя һәм беркетмә Кайбыч муниципаль район Советы материалларында билгеләнгән тәртиптә саклана.

17. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә Кайбыч муниципаль район Советының законлылык, регламент һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясе тарафыннан әзерләнә.

18. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыгарга тиеш.

19. Гавами тыңлаулар үткәрүне оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы Аппараты һәм Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.